| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.03.2022 с.Старое Дрожжаное №163

Законсыз рәвештә саклана торган яки табылган корал, хәрби припаслар, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен акчалата түләү турында Карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты үз көчен югалткан дип тану турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 17 гыйнварындагы 14 номерлы карары белән расланган законсыз рәвештә саклана торган яки табылган корал, хәрби припаслар, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен акчалата түләү турында Карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар имза салынган көннән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе: Д.А. Сатдинов